| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>СТАРОДРОЖЖАНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИСКЕ ЧҮПРӘЛЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

---

**РЕШЕНИЕ** с. Старое Дрожжаное **КАРАР**

20.12.2023 ел № 41/2

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы башкарма комитетына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләр (вәкаләтләр өлеше) тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы тәкъдимен кабул итәргә: - җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт төзү;

- җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслашкан хезмәт эшчәнлеге тәртибен билгеләү;

- җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге сыйфатына таләпләрне раслау;

- җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау;

- ир яисә хатын, якын туганнары, башка туганнары йә үлгән кешенең законлы вәкиле булмаган яисә аларны күмү мөмкин булмаган очракта үлгән (һәлак булган) мәетне күмү хезмәтләре бәясен раслау, шулай ук, үз өстенә күмү бурычын гамәлгә ашыру бурычын алган башка затлар булмаганда, өйдә, урамда

яисә аның эчке эшләр органнары тарафыннан билгеләнгәннән соң башка урында күмгәндә хезмәт күрсәтүләр бәясен раслау;

- шәхесе эчке эшләр органнары тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокларда билгеләнмәгән үлгән (һәлак булучыларны) күмү хезмәтләре бәясен раслау.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүрәле авыл җирлеге башкарма комитеты:

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә; әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында бюджет законнары нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советының 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге бюджеты турындагы карары проектында финанслауны күздә тотарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында Иске Чүпрәле авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварында үз көченә керә.

Иске Чүпрәле авыл җирлеге
Башлыгы Урынбасары: Р.Д.Низамов